**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Симәк авыл җирлеге Симәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

16 ноябрь 2023 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2023 елның 16 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2024 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Симәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500,00 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 750,00 (җиде йөз илле) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән, һәм махсус хәрби операция кысаларында контракт төзегән гражданнарны, һәм шулай ук хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

**1. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау һәм тоту:**

- Симәк авылы эчендә Кооператив, Мәктәп һәм Яшьләр урамнарында, су башнясына һәм зиратка кадәр эчке кышкы юлларны карап тоту, кар чистартуга килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;
- Симәк авылы эчендә Кооператив, Мәктәп һәм Яшьләр урамнарында, су башнясына һәм зиратка кадәр автомобиль юлларын җәйге тоту;
- Кооператив һәм Яшьләр урамнарында юлларны грейдирлау һәм юлга вак таш салу;
- Симәк авылының Мәктәп урамына юл билгеләре кую;
- Симәк авылы юллары кырыйларында үскән үләннәрне чабу

**2. Урам яктырту челтәрләрен ремонтлау:**

-Кооператив, Мәктәп һәм Яшьләр урамнары буенча тышкы яктырту урам челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау;
- светодиодлы лампалар, кронштейннар һәм комплектлау материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү.

**3. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:**

- Симәк авылы, Мәктәп урамы, 8а йорты адресы буенча урнашкан Симәк авыл мәдәният йорты территориясен төзекләндерү,
- мәдәният йорты янында автомобиль парковкасын җиһазландырырга;
- Мәктәп урамында сквер коймасын яңарту;
- массакүләм ял итү урыннарында үлән чабу.

**4. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү:**

- Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарның исемнәре язылган такталар урнаштыру;
- кыргый үсентеләрне һәм карт агачларны кистерү;
- Симәк авылындагы зиратның коймаларын ремонтлау һәм яңарту;

- традицион күмү урыннарын чабу;
- каты коммуналь калдыкларны чыгару.

**5. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**

- Симәк авылы Кооператив, Мәктәп урамнарында гидрантлар урнаштыру;
- янгын сүндерү машинасын тоту.

**6. Яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту:**

- сулык янында куакларны кисү;
- чүбен түгү.

**7. Су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манарасын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче скважиналарны проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

- Симәк авылының Кооператив, Мәктәп, Яшьләр урамнарында суүткәргеч челтәрен ремонтлау;
- Симәк авылында эчәр суның сыйфатын лаборатор тикшерүләр үткәрү;
- су күтәрү манарасының электр энергиясе өчен түләү;

**8. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү:**

- Симәк авылы янындагы чишмәне төзекләндерү.

**9. Мирас һәйкәлләрен төзү һәм ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү:**

- Симәк авылы Мәктәп урамында урнашкан Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәлне ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 143_кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 74, бу 52% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 71 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 3 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл жирлегенең Симәк торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл жирлеге Симәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500,00 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 750,00 (җиде йөз илле) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән, һәм махсус хәрби операция кысаларында контракт төзегән гражданнарны, һәм шулай ук хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

**1. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау һәм тоту:**

- Симәк авылы эчендә Кооператив, Мәктәп һәм Яшьләр урамнарында, су башнясына һәм зиратка кадәр эчке кышкы юлларны карап тоту, кар чистартуга килешү буенча хезмәтләр өчен түләү;
- Симәк авылы эчендә Кооператив, Мәктәп һәм Яшьләр урамнарында, су

башнясына һәм зиратка кадәр автомобиль юлларын җәйге тоту;

- Кооператив һәм Яшьләр урамнарында юлларны грейдирлау һәм юлга вак таш салу;

- Симәк авылының Мәктәп урамына юл билгеләре кую;

- Симәк авылы юллары кырыйларында үскән үләннәрне чабу

**2. Урам яктырту челтәрләрен ремонтлау:**

-Кооператив, Мәктәп һәм Яшьләр урамнары буенча тышкы яктырту урам челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау;

- светодиодлы лампалар, кронштейннар һәм комплектлау материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү.

**3. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:**

- Симәк авылы, Мәктәп урамы, 8а йорты адресы буенча урнашкан Симәк авыл мәдәният йорты территориясен төзекләндерү,

- мәдәният йорты янында автомобиль парковкасын җиһазландырырга;

- Мәктәп урамында сквер коймасын яңарту;

- массакүләм ял итү урыннарында үлән чабу.

**4. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү:**

- Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарның исемнәре язылган такталар урнаштыру;

- кыргый үсентеләрне һәм карт агачларны кистерү;

- Симәк авылындагы зиратның коймаларын ремонтлау һәм яңарту;

- традицион күмү урыннарын чабу;

- каты коммуналь калдыкларны чыгару.

**5. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**

- Симәк авылы Кооператив, Мәктәп урамнарында гидрантлар урнаштыру;

- янгын сүндерү машинасын тоту.

**6. Яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту:**

- сулык янында куакларны кисү;

- чүбен түгү.

**7. Су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манарасын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче скважиналарны проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

- Симәк авылының Кооператив, Мәктәп, Яшьләр урамнарында сууткәргеч челтәрен ремонтлау;

- Симәк авылында эчәр суның сыйфатын лаборатор тикшерүләр үткәрү;

- су күтәрү манарасының электр энергиясе өчен түләү;

**8. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү:**

- Симәк авылы янындагы чишмәне төзекләндерү.

**9. Мирас һәйкәлләрен төзү һәм ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү:**

- Симәк авылы Мәктәп урамында урнашкан Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәлне ремонтлау.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Симәк авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Садертдинов